КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 апрель г.Казань № 319

Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1640 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:
Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибе;
Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибе.
2. Үз көчләрен югалткан дип танырга:
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 26 июнь, 516 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 26 июнь, 516 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 22 ноябрь, 1064 нче карары.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдәтотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 22 апрель, 319 нчы
карары белән расланды

Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Россия Федерациясе гражданнары булган, максатчан укыту турында шартнамә буенча үтәлмәгән финанс йөкләмәләре булмаган (штатның 60 проценттан кимрәге комплектланган медицина оешмаларыннан тыш), авыл торак пунктларына, йә эшчеләр поселокларына, йә шәһәр тибындагы поселокларга, йә 50 меңгә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күчкән) һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 350 статьясы нигезендә билгеләнгән эш вакыты дәвамлылыгы белән тулы эш көне шартларында, медицина оешмаларында һәм аларның структур бүлекчәләрендә медицина хезмәткәрләренең вакантлы вазыйфалары исемлегенә кертелгән, аларны биләгәндә чираттагы финанс елына бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре гамәлгә ашырыла торган вазыйфаларда (алга таба – вазыйфаларның программалы реестры) хезмәт функцияләрен үтәү белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган медицина оешмасы (алга таба – медицина оешмалары) белән хезмәт шартнамәсе төзегән медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм федераль бюджеттан субсидияләр (алга таба – акчалар) исәбеннән күрсәтелгән чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган акчалар (алга таба – бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре) исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын төп бүлүче булып Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тора.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру чараларын финанс белән тәэмин итүгә акча җибәрә.

5. Акчаларны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счет аша башкарыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы

Сәламәтлек саклау министрлыгына финанслауның иң чик күләмнәрен, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре чикләрендә җиткерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында:

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосындагы бюджет һәм автоном учреждениеләр булган медицина оешмалары белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.[1] статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яисә автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешүнең типлаштырылган формасын раслау хакында» 2016 елның 22 декабрендәге 17-148 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча акча бирү турында килешүләр төзи;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча чарада катнашу өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган чарада катнашучыларның (табибларның, фельдшерларның) планлаштырылган саны турында белешмәләрне үз эченә алган гариза тапшыра;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2020 ел, 21 февраль, 115н номерлы боерыгы белән расланган беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче медицина оешмаларында һәм аларның структур бүлекчәләрендә аларны биләгәндә чираттагы финанс елына бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре гамәлгә ашырыла торган вазыйфаларның медицина хезмәткәрләре вазыйфаларының якынча исемлеге нигезендә эшләнгән вазыйфаларның программ реестрын раслый;

медицина оешмасы һәм медицина хезмәткәре белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча бер тапкыр бирелә торган компенсацион түләү бирү турында шартнамә төзи;

медицина оешмаларына акча күчерә.

8. Медицина оешмалары квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның бишенче числосыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча хисаплар тапшыра:

акчадан файдалану турында;

акчадан файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында.

9. Акчаларны максатсыз файдалану бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

10. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина оешмалары тарафыннан бирелгән чараларны түбәндәге очракларда өлешчә яисә тулысынча кире кайтаруны тәэмин итә:

күрсәтелгән чараларга ихтыяҗның булмавы (кимүе);

медицина оешмалары тарафыннан дөрес хисап бирмәү;

медицина оешмалары тарафыннан чаралардан максатсыз файдалану.

11. Әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән очракларда медицина оешмаларына бирелгән акчалар Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбен алган көннән алып 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмалары тарафыннан акчаны кире кайтару сроклары бозылганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 30 көн эчендә акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

12. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итүгә кергән акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны тәэмин итәләр.

13. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына акчалардан файдалану һәм акчалардан нәтиҗәле файдалану күрсәткечләренә ирешү турында хисапларны Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган «Сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына акчалар бирү турында килешүдә билгеләнә торган формалар буенча тапшыра.

14. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм медицина оешмаларына йөкләнә.

___________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 22 апрель, 319 нчы
карары белән расланды

Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Россия Федерациясе гражданнары булган, максатчан укыту турында шартнамә буенча үтәлмәгән финанс йөкләмәләре булмаган (штатның 60 процентган кимрәге комплектланган медицина оешмаларыннан тыш), авыл торак пунктларына, йә эшчеләр поселокларына, йә шәһәр тибындагы поселокларга, йә 50 меңгә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күчкән) һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 350 статьясы нигезендә билгеләнгән эш вакыты дәвамлылыгы белән тулы эш көне шартларында, медицина оешмаларында һәм аларның структур бүлекчәләрендә медицина хезмәткәрләренең вакантлы вазыйфалары исемлегенә кертелгән, аларны биләгәндә чираттагы финанс елына бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре гамәлгә ашырыла торган вазыйфаларда хезмәт функцияләрен үтәү белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына караган медицина оешмасы (алга таба – медицина оешмалары) белән хезмәт шартнамәсе төзегән медицина хезмәткәрләренә түбәндәге күләмдә билгеләнә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасының ерак һәм ерак булган территорияләре исемлеге нигезендә авыл торак пунктларына, йә эшчеләр поселокларына, йә шәһәр тибындагы поселокларга эшкә килгән табиблар өчен 1,5 млн. сум һәм фельдшерлар өчен 0,75 млн. сум акча;

авыл торак пунктларына, йә эшчеләр поселокларына, йә шәһәр тибындагы поселокларга, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгәннәрдән тыш, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән табиблар өчен 1 млн.сум һәм фельдшерлар өчен 0,5 млн.сум акча.

3. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән табибка бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүе күләме ($V_{вр}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{вр} = 1 \times L \quad и \quad V_{вр} = 1,5 \times L,$$

монда:

1 – табибка бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең күләме 1,0 млн. сум тәшкил итә;

1,5 – табибка бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең күләме 1,5 млн. сум тәшкил итә;

L – авыл торак пунктларына, йә эшчеләр поселокларына, йә шәһәр тибындагы поселокларга, йә 50 меңгә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күчкән) медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына акчалар бирү турындагы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган килешү (алга таба – килешү) нигезендә билгеләнә торган федераль бюджеттан Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслауның иң чик дәрәҗәсе.

Федераль бюджеттан субсидия исәбенә табибка бирелә торган бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүе күләме (Vвф) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{вф} = 1 – V_{вр} \quad и \quad V_{вф} = 1,5 – V_{вр},$$

монда:

1 – табибка бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең күләме 1,0 млн. сум тәшкил итә;

1,5 – табибка бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең күләме 1,5 млн. сум тәшкил итә;

$V_{вр}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән табибка бирелә торган бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең күләме.

4. Фельдшерга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүе күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{фр} = 0,5 \times L \quad и \quad V_{фр} = 0,75 \times L,$$

монда:

0,5 – фельдшерга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең күләме 0,5 млн. сум тәшкил итә;

0,75 – фельдшерга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең күләме 0,75 млн. сум тәшкил итә;

L – Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәсен федераль бюджеттан финанслауның килешү нигезендә билгеләнә торган иң чик дәрәҗәсе.

Фельдшерга федераль бюджет акчасы исәбеннән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүе күләме ($V_{фф}$) түбәндәге формулалар буенча исәпләнә:

$$V_{фф} = 0,5 – V_{фр} \quad и \quad V_{фф} = 0,75 – V_{фр},$$

монда:

0,5 – фельдшерга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең күләме 0,5 млн. сум тәшкил итә;

0,75 – фельдшерга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвенең күләме

0,75 млн. сум тәшкил итә;

$V_{фр}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән фельдшерга бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүе.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен бирү буенча һәм медицина оешмасы һәм медицина хезмәткәре белән бер тапкыр компенсация түләү турында шартнамәләр (алга таба – шартнамә) төзү буенча буенча вәкаләтле орган булып тора.

6. Медицина оешмалары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына шартнамәне төзүгә документлар һәм гариза җибәрәләр.

7. Бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан медицина хезмәткәре йөкләмәләрне кабул итә торган шартнамә нигезендә бер тапкыр бирелә:

а) хезмәт функциясен тулысынча үтәмәгән чорга килешүне озайту шарты белән (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 106 һәм 107 статьяларында каралган ял вакытыннан тыш) хезмәт килешүе нигезендә вазыйфага килешү төзелгән көннән алып биш ел эчендә хезмәт вазыйфаларын үтәргә;

б) хезмәт шартнамәсе туктатылганнан соң 30 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына хезмәт шартнамәсе беткәннән соң биш еллык срокка кадәр пропорциональ эшләп бетерелмәгән чорга исәпләнгән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүсенең бер өлешен кире кайтарырга (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешенең 8 пунктында һәм 83 статьясындагы беренче өлешенең 5 – 7 пунктларында каралган нигезләр буенча хезмәт шартнамәсе туктатылу очракларыннан тыш), шулай ук башка вазыйфага күчергән яисә өстәмә һөнәри программалар буенча укуга кергән очракта, кире кайтарырга;

в) хезмәт шартнамәсе туктатылганнан соң 30 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына хезмәт шартнамәсе туктатылганнан соң, хәрби хезмәткә чакырылуга бәйле рәвештә, эштән азат ителгән көннән үк пропорциональ эшкәртелмәгән чорга (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 83 статьясындагы беренче өлешенең 1 пункты нигезендә) яисә шартнамәнең гамәлдә булу срогын функциональ бурычларны үтәмәгән чорга исәпләнгән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүенең бер өлешен кире кайтарырга (медицина хезмәткәре сайлау буенча).

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләвен бирү турында карар кабул итәргә хокуклы:

а) максатчан укыту (максатчан әзерлек) белән бәйле йөкләмәләре булганда, штатның комплектлануы 60 проценттан ким булган медицина оешмасы белән хезмәт килешүе төзү шарты белән аның карамагында булган;

б) максатчан укыту (максатчан әзерлек) белән бәйле йөкләмәләрне үтәгән медицина хезмәткәре тарафыннан авыл торак пунктында, эш бистәсендә яки шәһәр тибындагы бистәдә, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрдә эшләүне дәвам итү шарты белән.

9. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен медицина оешмаларына субсидияләр рәвешендә акча күчерә.

10. Медицина оешмалары үз счетларына акчалар кергәннән соң 10 эш көне эчендә аларның исәбенә алынган бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләрен кредит оешмасында медицина хезмәткәре тарафыннан ачылган счетка күчерәләр.

11. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина хезмәткәре белән хезмәт шартнамәсен туктатканда (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьяның беренче өлешендәге 8 пунктында, 83 статьяның беренче өлешендәге 5 – 7 пунктларында каралган нигезләр буенча хезмәт шартнамәсе туктатылу очракларыннан тыш), шулай ук башка вазыйфага күчергәндә яки өстәмә һөнәри программалар буенча укырга кергән очракта, хезмәт килешүе туктатылган датадан исәпләнгән бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре өлешендә, медицина хезмәткәре эшләмәгән чорга пропорциональ рәвештә бирелгән субсидияләрне өлешчә (тулы) кире кайтаруны тәэмин итә.

12. Бирелгән акчалар, әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән фактларны ачыклаган очракта, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбен алган көннән алып, 15 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидияләр алучылар тарафыннан субсидияләрне кире кайтару срогы бозылганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына күрсәтелгән акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә алу чараларын күрә.

13. Бюджет акчаларының максатчан кулланылышын тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнә.

___________________________________